**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 12 март № 148

г. Казань

Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре җитәкчеләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында

Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре җитәкчеләренең хезмәт өчен түләү шартларын тәртиптә китерү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре җитәкчеләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне (алга таба – Нигезләмә) расларга.

2. Дәүләт унитар предприятиеләрен гамәлгә куючы (мөлкәт милекчесе) вәкаләтләрен башкаручы Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарына(алга таба – Гамәлгә куючы):

дәүләт унитар предприятиеләре җитәкчеләре белән хезмәт шартнамәләре төзегәндә Нигезләмәгә таянырга;

дәүләт унитар предприятиеләре җитәкчеләре белән хезмәт шартнамәләренә, аларны Нигезләмәгә туры китерү максатыннан чыгып, билгеләнгән тәртиптә үзгәрешләр кертү чараларын 6 ай эчендә гамәлгә ашырырга;

бу карар үз көченә кергән көннән 3 ай эчендә үз норматив хокук актларын Нигезләмәгә туры китерергә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре җитәкчеләрен билгеләү, алар белән хезмәт шартнамәләре төзү, аларны аттестацияләү тәртибе турында» 2009 ел, 16 июль, 496 нчы карарының (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 31 декабрь, 922 нче; 2010 ел, 10 сентябрь, 725 нче; 2013 ел, 31 октябрь, 820 нче; 2013 ел, 13 декабрь, 982 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) 3 нче пунктындагы дүртенче абзацы үз көчен югалткан дип санарга.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\148.docx

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 12 март, 148 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре җитәкчеләренең
хезмәт өчен түләү шартлары турында
нигезләмә

1. Бу Нигезләмә дәүләт унитар предприятиеләре (алга таба – Предприятие) җитәкчеләренең алар белән хезмәт шартнамәләре төзегәндә хезмәт өчен түләү шартларын, шулай ук Предприятие җитәкчеләренең, җитәкчеләре урынбасарларының һәм баш бухгалтерларының уртача эш хакы белән Предприятиенең исемлек буенча составындагы хезмәткәрләренең уртача эш хакы чагыштырмасының иң чик дәрәҗәсен билгели.

2. Предприятие җитәкчеләренең хезмәт өчен түләве вазыйфаи окладны һәм стимуллаштыру һәм компенсация характерындагы түләүләрне үз эченә ала.

3. Предприятие җитәкчесенең вазыйфаи окладны күләме гамәлгә куючы (мөлкәт милекчесе) вәкаләтләрен башкаручы дәүләт хакимияте органы (алга таба – Гамәлгә куючы) тарафыннан хезмәтнең катлаулылыгына, идарә итү масштабына һәм эшчәнлегенең үзенчәлекләренә һәм Предприятиенең әһәмиятенә карап билгеләнә.

4. Предприятиеләр җитәкчеләре өчен компенсация характерындагы түләүләр Россия Федерациясе Хезмәт кодексы һәм Гамәлгә куючының хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокук актлары белән күздә тотылган тәртип һәм күләмнәр нигезендә билгеләнә.

5. Предприятие җитәкчеләрен бүләкләү өчен, Предприятие уставы белән билгеләнгән төп бурычларны һәм функцияләрне үтәүдә Предприятие җитәкчесе керткән шәхси өлешне исәпкә алып, Гамәлгә куючы тиешле ел өчен раслаган Предприятие эшчәнлегенең икътисадый нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә Предприятие тарафыннан ирешү нәтиҗәләре буенча гамәлгә ашырыла торган стимуллаштыру характерындагы түләүләр  билгеләнә.

Стимуллаштыру характерындагы түләүләрнең күләме һәм аларны бирү ешлыгы, Предприятие эшчәнлегенең икътисадый нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешүне исәпкә алып, Гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә.

6. Предприятие җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының һәм баш бухгалтерларының уртача эш хакы белән Предприятиенең исемлек буенча составындагы хезмәткәрләренең (җитәкчене, җитәкче  урынбасарларын һәм баш бухгалтерны исәпкә алмыйча) уртача эш хакы чагыштырмасының чик дәрәҗәсе Гамәлгә куючы тарафыннан 1 дән 8 тапкырга кадәр билгеләнә.

Предприятие җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының һәм баш бухгалтерларының уртача эш хакы белән Предприятиенең исемлек буенча составындагы хезмәткәрләренең уртача эш хакы чагыштырмасы календарь ел өчен хисаплап чыгарыла.

Предприятиедә уртача эш хакы исемлек буенча составтагы хезмәткәрләрнең (җитәкчене, җитәкче урынбасарларын һәм баш бухгалтерны исәпкә алмыйча) исәпләнгән эш хакы фондын календарь ел өчен күрсәтелгән хезмәткәрләрнең уртача санына бүлү юлы белән хисаплап чыгарыла.

7. Предприятие җитәкчесе вазыйфаларын җитәкче урынбасарына яки бу Предприятиенең башка хезмәткәренә йөкләгәндә өстәмә түләү күләме хезмәт шартнамәсе яклары килешүе буенча билгеләнә.

---